**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**“Новотроицк авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлек Советы**

# КАРАРЫ

24 нче сентябрь 2018 нче ел  Новотроицк авылы  № 30/5

«Новотроицк авыл җирлегендә җирле референдум билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 нчы статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 нче елның 12 нче июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20,35 че статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 нче елның 25 нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 нче статьясы, Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 нче елның 23 нче сентябрендәге 15 нче номерлы карары белән, Новотроицк авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге 30/4 нче номерлы карары, Новотроицк авыл җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы,

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Новотроицк авыл җирлегендә 2018 нче елның 18 нче ноябрендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләргә.
2. Новотроицк авыл җирлеге муниципаль берәмлек Советы Новотроицк авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Новотроицк авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инциативасында референдум сорауларын түбәндәгечә формалаштырып тәкъдим итәргә:

   «Сез 2019 нчы елда Новотроицк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, күп балалы гаиләләр, ялгыз карт гражданнар, көндезге формада укучы студентлар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә ризамы, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә дигән тәкъдим белән сез килешәсезме:
   - Новотроицк авылында янгын сүндерү депосы төзү;
   - Новотроицк һәм Шөкрәле авыллырында юлларны ремонтлау;
   - Авыл җирлегенә кергән зиратларга хуҗалык кирәк-яраклары алу;
   - Күперле авылы зиратын әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу;
   - Авыл җирлегенә кергән торак пунктларда урам утларын төзекләндерү.»
3. Референдум әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссиясенә йөкләргә:
   - муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге участок сайлау комиссиясенә.

4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Новотроицк авыл җирлеге бюджеты хисабына тормышка ашырырга.
5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында игълан итәргә.
7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р. Р. Волкова

: